**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№222**
**22.01.2020**

2020 елда Яр Чаллы шәһәре
территориясендә авыл
хуҗалыгы ярминкәләре
үткәрүне оештыру турында

Шәһәр халкын авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү, авыл хуҗалыгы производствосында һәм эшкәртү сәнәгатендә эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү, авыл товар җитештерүчеләренә, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыгы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы яки бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүче гражданнарга ярдәм күрсәтү максатында, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү урыннары исемлеген, 1 нче кушымтада каралганча;

2) мәйданчыкларда сәүдә урыннарының урнашу схемасын, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә Башкарма комитетның район хакимиятләре белән берлектә, авыл хуҗалыгы ярминкәләренә авыл товар җитештерүчеләрен, азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгате, сәүдә, җәмәгать туклануы һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләрен, шәхси эшмәкәрләрне, шулай ук бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнүче, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны җәлеп итүне тәэмин итәргә.

3. «Горкоммунхоз» муниципаль унитар предприятиесенә, «Автомобиль юллары предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесенә авыл

хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү урыннарын әзерләүне һәм тиешле санитар хәлдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Тәкъдим итәргә:

1) «Шәһәр яшелләндерү хуҗалыгы» ачык акционерлык җәмгыятенә, «Родник-АЗС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү урыннарын әзерләүне һәм тиешле санитар хәлдә тотуны тәэмин итәргә;

2) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы идарәсенә авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү урыннарында гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә;

3) Татарстан Республикасы буенча Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең Яр Чаллы шәһәрендәге территориаль бүлегенә, Татарстан Республикасы буенча ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча Федераль хезмәт идарәсенә (Яр Чаллы шәһәре буенча), «Яр Чаллы шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә сатыла торган продукциянең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына карата гамәлдәге закон таләпләрен үтәү чараларын тәэмин итәргә;

5. Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенә авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү урыннары турында халыкка җиткерергә.

6. Авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү урыннарын әзерләү һәм тиешле санитар хәлдә тоту, сәүдә итү мәйданчыкларын парковкадагы автотранспорттан арындыру, ярминкәдә катнашучыларның автотранспорт чараларын урнаштыру, авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча чаралар үткәрү өчен җаваплылыкны Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыклары А.И. Кисловка, И.Н. Галимовка, В.Х. Харисовка йөкләргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2020 елның 22 гыйнварындагы
222 номерлы карарына
1 нче кушымта

2020 елда Яр Чаллы шәһәре территориясендә
авыл хуҗалыгы ярминкәләрен үткәрү урыннарының
исемлеге


| Т/с | Ярминкәне оештыручының исеме һәм юридик адресы | Үткәрү урыны | Ярминкәнең тибы, төре | Үткәрү сроклары | Сәүдә урыннарының саны | Эш режимы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 | Үзәк районы:<br><br>Яр Чаллы шәһәре, Әхмәтшин урамы,115 адресы буенча урнашкан «Южный» агросәнәгать паркы | «Кышкы» авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>8 февральдән 29 февральгә кадәр («Родник» АЗС ҖЧҖ белән килешү буенча) | 120 | 8.00 дән 15.00 сәгатькә кадәр |
| 2. | | | «Язгы» авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>7 марттан 25 апрельгә кадәр («Родник» АЗС ҖЧҖ белән килешү буенча) | | |
| 3. | | | «Уңыш-2020» авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>12 сентябрьдән 27 декабрьгә кадәр («Родник» АЗС ҖЧҖ белән килешү буенча) | | |
| 4. | | Комсомол районы:<br><br>Тукай яр буе, «Төзүче» стадионы каршындагы мәйданчык | «Кышкы» авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>8 февральдән 29 февральгә кадәр | 200 | 8.00 дән 15.00 сәгатькә кадәр |
| 5. | | | «Язгы» авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>7 марттан 25 апрельгә кадәр | | |
| 6. | | | «Уңыш-2020» авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>12 сентябрьдән 27 декабрьгә кадәр | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | | | «Яңа ел казы» махсуслаштырылган тематик ярминкә | - 19, 20, 26, 27 декабрь | | |
| 8. | | Автозавод районы:<br><br>Чулман проспекты, Ипподром территориясе | «Кышкы» авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>8 февральдән 29 февральгә кадәр | 280 | 8.00 дән<br>15.00 сәгатькә кадәр |
| 9. | | | «Язгы»<br>авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>7 марттан 25 апрельгә кадәр | | |
| 10. | | | «Бал»<br>махсуслаштырылган тематик ярминкә | - көн саен:<br>15 августтан 23 августка кадәр | | |
| 11. | | | «Уңыш-2020»<br>авыл хуҗалыгы ярминкәсе | - атна саен шимбә көннәрендә:<br>12 сентябрьдән 27 декабрьгә кадәр | | |
| 12. | | | «Яңа ел казы»<br>махсуслаштырылган тематик ярминкә | - 19, 20, 26, 27 декабрь | | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 22 гыйнварындагы
222 номерлы карарына
2 нче кушымта


«Южный» агросәнәгать паркы районында
сәүдә урыннарының урнашу схемасы



Габдулла Тукай яр буенда «Төзүче» стадионы каршындагы мәйданчыкта
сәүдә урыннарының урнашу схемасы



Ипподром территориясендә
сәүдә урыннарының урнашу схемасы




Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова